**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**СОВЕТ**
**Нижнекамского муниципального района**

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Түбән Кама муниципаль районы**
**СОВЕТЫ**

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

**РЕШЕНИЕ**

**КАРАР**

**№ 34** **2019 елның 6 июне**

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Советының 2016 елның 21 мартындагы 12 номерлы карары (Түбән Кама муниципаль районы Советының 2016 елның 20 октябрендәге 59 номерлы, 2017 елның 24 гыйнварындагы 3 номерлы, 2018 елның 21 февралендәге 10 номерлы, 2018 елның 17 маендагы 38 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль районы Советының 2016 елның 21 мартындагы 12 номерлы карары (Түбән Кама муниципаль районы Советының 2016 елның 20 октябрендәге 59 номерлы, 2017 елның 24 гыйнварындагы 3 номерлы, 2018 елның 21 февралендәге 10 номерлы, 2018 елның 17 маендагы 38 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәт үтүгә кагылышлы норматив хокукый актларын әлеге карарга туры китерергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирле үзидарә, регламент һәм хокук тәртибе мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль районы Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы,
район Башлыгы урынбасары

Э.Р.Долотказина

Түбән Кама муниципаль районы
Советының
2019 елның 6 июне
34 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы
Түбән Кама муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә
үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. «Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләре» 6 статьясында:

1) 6.2 пунктның 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) муниципаль хезмәт стажына яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына:

муниципаль хезмәтнең иң югары вазыйфалары буенча - ике елдан ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча дүрт елдан да ким булмаган эш стажы;

муниципаль хезмәтнең төп вазыйфалары буенча – бер елдан ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча ике елдан ким булмаган эш стажы.»;

2) 6.3 пуктында «өлкән» сүзен «әйдәп баручы, өлкән» сүзләренә алмаштырырга;

3) 6.5 пунктында «муниципаль хезмәтнең әйдәүче вазыйфаларын биләү өчен - ярты елдан ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яки белгечлек буенча бер ел эш стажы» сүзләрен «, муниципаль хезмәтнең төп вазыйфаларын биләү өчен әзерлек юнәлеше - ярты елдан ким булмаган муниципаль хезмәт стажы яки белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча бер ел эш стажы» сүзләренә алмаштырырга;

4) түбәндәге эчтәлекле 6.6, 6.7 пунктлары белән тулыландырырга:

«6.6. Әгәр муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи инструкциясе тарафыннан муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен кирәк булган белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә квалификация таләпләре каралган булса, белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажын исәпләгәндә, әлеге стажга гражданның (муниципаль хезмәткәрләрнең) белем алу һәм (яки) әлеге белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча квалификациясе турында документ алганнан соң әлеге белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эшләү чорлары кертелә.

6.7. Әгәр муниципаль хезмәткәрнең вазыйфаи инструкциясе тарафыннан белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча квалификация таләпләре каралмаган булса, белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажын исәпләгәндә, әлеге стажга гражданның (муниципаль хезмәткәрләрнең) аны үтәгәндә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләренә туры килә торган әлеге дәрәҗәдәге һөнәри белем турында документ алганнан соң, муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча хезмәт вазыйфаларын башкару өчен кирәкле белем һәм осталык алынган эш чоры кертелә.».

2. «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыру» 14 статьясында:

1) пунктларны номерлауны «14.1, 14.2, 14.3, 14.3, 14.4, 14.5, 14.6, 14.7, 14.8, 14.9, 14.10» нан «14.1, 14.2, 14.3, 14.4, 14.5, 14.6, 14.7, 14.8, 14.9, 14.10, 14.11» номерлауга алмаштырырга;

2) 14.10 пунктында «14.7 пункты нигезендә» сүзләрен «14.8 пункты нигезендә» сүзләренә алмаштырырга;

3) 14.11 пунктында «14.9 пункты нигезендә» сүзләрен «14.10 пункты нигезендә» сүзләренә алмаштырырга.

3. «Муниципаль берәмлектә муниципаль хезмәткәрләр реестры» 32 статьясында 32.4 пунктында «Татарстан Республикасы» сүзләрен төшереп калдырырга.

Түбән Кама муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Э.Р.Долотказина